**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 1 августындагы 3206 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2019 елның 21 августындагы 2965 номерлы**
**«2019-2023 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге**
**торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча**
**муниципаль адреслы программаны раслау турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2019-2023 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны гамәлгә ашыру этапларын финанслау күләмнәрен төгәлләштерүгә бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 21 августындагы 2965 номерлы «2019-2023 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 6 сентябрендәге 3114 номерлы, 2019 елның 16 декабрендәге 4488 номерлы, 2020 елның 21 апрелендәге 1185 номерлы, 2020 елның 23 декабрендәге 3811 номерлы, 2021 елның 2 июнендәге 1382 номерлы, 2021 елның 18 июнендәге 1508 номерлы, 2021 елның 16 сентябрендәге 2357 номерлы, 2022 елның 27 декабрендәге 4670 номерлы, 2023 елның 15 сентябрендәге 2701 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1. Территорияләрне үстерү фонды һәм Татарстан Республикасы бюджеты чаралары хисабыннан Программаны гамәлгә ашыруга Министрлыктан Казан шәһәре бюджетына 949 673 057,72 сум күләмендә [шул исәптән 2019 елда – 129 588 525,00 сум, 2020 елда – 144 618 600,00 сум, 2021 елда – 665 984 159,12 сум (шулардан 2021 ел этабы буенча – 221 189 463,00 сум һәм 2022 ел этабы буенча – 444 794 696,12 сум), 2022 елда – 2022 ел этабы буенча 2 802 610,80 сум, 2023 елда – 2022 ел этабы буенча 914 166,00 сум, 2024 елда – 2022 ел этабы буенча 5 764 996,80 сум] акча күчерүне тәэмин итәргә»;

1.2. 2.2.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.2.2. милекчеләрдән билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлекләрен һәм торак урыннарны сатып алу өчен – 9 934 348,60 сум күләмендә акча (шул исәптән 2019 ел этабы буенча – 452 575,00 сум, 2022 ел этабы буенча – 9 481 773,60 сум, шуларның 2022 елда – 2 802 610,80 сум, 2023 елда – 914 166,00 сум, 2024 елда – 5 764 996,80 сум)»;

1.3. 2.2(1) пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.2(1). Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенә Казан шәһәре Башкарма комитетының резерв фонды акчалары хисабыннан торак урыннарны билгеләнгән тәртиптә алу өчен 8 228 719,28 сум күләмендә, шул исәптән 2021 елда – 6 836 840,88 сум (шулардан 2021 ел этабы буенча – 2 234 237,00 сум һәм 2022 ел этабы буенча – 4 602 603,88 сум), 2022 ел этабы буенча милекчеләрдән җир кишәрлекләрен һәм торак урыннарны билгеләнгән тәртиптә сатып алу өчен – 1 391 878,40 сум, шул исәптән 2022 елда – 28 309,20 сум, 2023 елда – 11 286,00 сум, 2024 елда – 1 352 283,20 сум күләмендә акча бүлеп бирергә»;

1.4. 3(1) пунктта «(С.А.Миронов)» сүзләрен «(В.В.Жаворонков)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**